| ГЛАВА САКЛОВ-БАШСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ САРМАНОВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ САРМАН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ САКЛАУБАШ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШЛАГЫ |
| --- | --- |

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

№ 8 05.11.2024

Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Саклаубаш авыл җирлеге Өчиле Саклау авылында 2025 нче елда гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча халык җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьялары, 18.1 статьясы нигезендә. Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Саклаубаш авыл җирлеге Уставы: нигезендә карар бирәм:

1. Өчөйле Саклау авыл клубы бинасында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын 15 нче ноябрь 2024 нчы ел 13:00 сәгатькә билгеләргә.. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга: «Саклаубаш авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган, I төркем инвалидларыннан тыш, 2024 елда үзара салым акчаларын кертүгә, вакытлы хәрби хезмәт үтүче гражданнардан, көндезге уку йортлары студентларыннан һәм алдагы эшләрне башкару буенча җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны җибәрүгә килешәсезме?:

1) Өчиле Саклау торак пунктына урам яктырту челтәрләрен ясау.

2) Халыкның массакүләм ял итү урыннарын төзекләү (триммер сатып алу)

3) автомобиль юлларын карап тору өчен МТЗ-82.1 махсус техникасын карап тоту (ягулык-майлау материаллары, запчастьләр сатып алу, машина йөртүчегә хезмәт хакы түләү, вак таш җәю);

ДА НЕТ?».

3. Әлеге карарны «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында» (PRAVO.TATARSTAN.RU) урнаштырырга. («Сарман муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең рәсми сайтында) һәм «Интернет» мәгълүмат

– телекоммуникация челтәрендә, Саклаубаш, Өчөйле Саклау, Алга, Яңа Саклау авылларында урнашкан махсус мәгълүмат стендларында.

4. Әлеге карар ул басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Саклаубаш авыл
җирлеге башлыгы Л.М.Габидуллина